РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БОЛЬШЕТАРХАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ТАРХАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 51-2-43, факс 51-2-43

# КАРАР

**8 ноябрь 2019 ел** **№ 1**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Олы Тархан авыл җирлегенең Түбән Тархан торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Олы Тархан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсенә нигезләнеп, **КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 22 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Тәтеш районы Түбән Тархан авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тархан авыл җирлегенең Түбән Тархан торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыены оештырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тархан авыл җирлегенең Түбән Тархан торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, I һәм II төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнар, иректән мәхрүм итү

урыннарындагы гражданнардан тыш,  2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм  аннан алынган акчаларны  җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез  риза буласызмы:

- Түбән Тархан авылы эчендәге юлларны төзекләндерү;
- Түбән Тархан авылында  буаны торгызу;
- Түбән Тархан авылында урамнарны яктырту өчен лампалар, ятырткычлар һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру;
- Түбән Тархан авылында  карт агачларны кисү ?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Олы Тархан авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълъмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Олы Тархан авыл җирлеге башлыгы** **А.М. Айзатуллов**